Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты.

# КАРАР

№ 4 19.02.2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының шәһәр тибындагы Аксубай поселогы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының шәһәр тибындагы Аксубай поселогы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2019 елның 01 ноябрендәге 15нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 26.12.2008 ел, 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 02.12.2019 ел, 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының шәһәр тибындагы Аксубай поселогы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы шәһәр тибындагы Аксубай поселогы Башкарма комитетының 01.11.2019 елның 15нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 3.3.3. пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында белдерү нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаганнан бирле".

2). 5.2. пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча, 02.05.2006 ел, 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 11статьясында, күрсәтелгән очраклардан тыш, язмача җавап бирә (27.12.2018 ел, редакциясендә)".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга://http:pravo.tatarstan.ru һәм Аксубай муниципаль районы сайтында урнаштырырга://http:aksubaevo.tatarstan.ru .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәһәр тибындагы Аксубай поселогы
Башкарма комитеты җитәкчесе: А.С.Большаков.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА АКСУБАЕВО